**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Азнакаевского муниципаль районы**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты**

Ленин ур., 22 й., Азнакай ш., 423330
Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**"21" октябрь 2022 ел** **№324**

2022 елның IV кварталына Азнакай муниципаль районы буенча гомуми торак мәйданының бер квадрат метры бәясенең нормативын билгеләү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 17 октябрендәге 1050 номерлы карары белән расланган, «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем сатып ала алырлык уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасының аерым чараларын гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатыннан, «Татарстан Республикасы бәяләүчеләр берлеге» коммерцияле булмаган партнерлыгының «Торак урыннарның бер квадрат метрының базар бәясенең уртача күрсәткечен билгеләү турында» 2022 елның 31 гыйнварындагы 23 номерлы тикшеренү нәтиҗәләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 03 октябрендәге 888 номерлы карары белән расланган, «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» дәүләт программасының «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү»ярдәмче программасын гамәлгә ашыру кысаларында яшь гаиләләргә торак сатып алуга социаль түләүләр бирү кагыйдәләренең 10 пункты нигезендә, карар итә:

1. Яшь гаиләләргә 2022 елның IV кварталына 31 178 (утыз бер мең йөз җитмеш сигез) күләмендә социаль түләү күләмен исәпләү өчен Азнакай муниципаль районы буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының бәясенә норматив билгеләргә.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы,
икътисад һәм финанслар буенча җитәкче урынбасары
О.Н. Газизова